**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2026 елның 10 августындагы 2827 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 5 апрелендәге 1372 номерлы карары белән расланган «Дорожный тыкрыгы һәм Зирекле урамы. Җиңү проспектыннан алып Архитектор Гайнетдинов урамына кадәр (1 нче этап) юл участогы» линия объекты территориясен планлаштыру проектына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 42, 45 һәм 46 статьялары нигезендә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2024 елның 2 февралендәге 112 номерлы «Федераль башкарма хакимиятнең вәкаләтле органнары, вәкаләтле Россия Федерациясе субъектларының башкарма органнары һәм җирле үзидарә органнары карарлары нигезендә әзерләнә торган территорияне планлаштыру документларын әзерләү, территорияне планлаштыру документларын раслау турында карар кабул итү, мондый документларга үзгәрешләр кертү, мондый документларны яки аның аерым өлешләрен гамәлдән чыгару, мондый документларның аерым өлешләрен кулланылырга тиеш түгел дип тану, шулай ук федераль һәм төбәк әһәмиятендәге тарихи җирлекләр территорияләренә карата территорияне планлаштыру проектын әзерләү һәм раслау кагыйдәләрен раслау турында»гы карарына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 елның 11 ноябрендәге 933 номерлы «Раслау турындагы карар Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә җирле үзидарә органнары тарафыннан кабул ителә торган территорияне планлаштыру проектлары һәм территорияне ызанлау проектлары, территорияне планлаштыруның мондый проектларына һәм территорияне ызанлау проектларына үзгәрешләр кертү җәмәгатьчелек белән фикер алышулар яисә ачык тыңлаулар уздырмыйча раслана торган очракларны билгеләү турында»гы карарына таянып, «“Алтын” махсуслаштырылган төзүче» акционерлык җәмгыяте гаризасы нигезендә **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2024 елның 5 апрелендәге 1372 номерлы карары (аңа Казан шәһәре Башкарма комитетының 2024 елның 5 апрелендәге 1372 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган «Дорожный тыкрыгы һәм Зирекле урамы. Җиңү проспектыннан алып Архитектор Гайнетдинов урамына кадәр (1 нче этап) юл участогы» линия объекты территориясен планлаштыру проектына, әлеге карарның кушымтасы нигезендә территорияне планлаштыру проектының аерым өлешләрен раслап, үзгәрешләр кертергә

2. Әлеге карарны, Казан шәһәре Башкарма комитетының 2024 елның 5 апрелендәге 1372 номерлы карары белән расланган «Дорожный тыкрыгы һәм Зирекле урамы. Җиңү проспектыннан алып Архитектор Гайнетдинов урамына кадәр (1 нче этап) юл участогы» линия объекты территориясен планлаштыру проектына кертелә торган үзгәрешләргә 2, 4 һәм 5 номерлы кушымталардан (хезмәт урынында файдалану өчен материаллар) кала, «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырып чыгарырга һәм аны Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) рәсми басылып чыкканнан соң гамәлгә керә дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесенең беренче урынбасары А.Р.Нигъмәтҗановка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2026 елның 10 августындагы
2827 номерлы карарына
кушымта

**Казан шәһәре Башкарма комитетының 2024 елның 5 апрелендәге 1372 номерлы карары белән расланган «Дорожный тыкрыгы һәм Зирекле урамы. Җиңү проспектыннан алып Архитектор Гайнетдинов урамына кадәр (1 нче этап) юл участогы» линия объекты территориясен планлаштыру проектына  кертелә торган үзгәрешләр**

1. Икенче абзацны түбәндәге редакциядә бирергә:

«I. Территорияне планлаштыру проекты. График өлеш. Кызыл линияләр, линия объектларын план буенча урнаштыру зоналары чикләре, урыннары үзгәрүгә бәйле рәвештә реконструкцияләнергә тиешле линия объектларын план буенча урнаштыру зоналары чикләре сызымы».

2. Кызыл линияләр, линия объектларын план буенча урнаштыру зоналары чикләре, урнашу урыннары үзгәрүгә бәйле рәвештә реконструкцияләнергә тиешле линия объектларын план буенча урнаштыру зоналары чикләре сызымын әлеге үзгәрешләргә 1 номерлы кушымта нигезендәге редакциядә бирергә.

3. Билгеләнә торган кызыл линияләрнең характерлы нокталары координаталары исемлеген әлеге үзгәрешләрнең 2 номерлы кушымтасы нигезендәге редакциядә бирергә.

4. IV «Линия объектларын урнаштыру турында нигезләмә» бүлегендә:

4.1. текст өлешен әлеге үзгәрешләргә 3 номерлы кушымта нигезендәге редакциядә бирергә;

4.2. планлаштыру проекты чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеген төшереп калдырырга;

4.3. линия объектын план буенча урнаштыру зоналары чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеген әлеге үзгәрешләргә 4 номерлы кушымта нигезендәге редакциядә бирергә;


4.4. урыннары үзгәрүгә бәйле рәвештә реконструкцияләнергә тиешле линия объектларын план буенча урнаштыру зоналары чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеген әлеге үзгәрешләргә 5 номерлы кушымта нигезендә редакцияләп бирергә;

__________________

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2024 елның 5 апрелендәге
1372 номерлы карары белән
расланган линия объекты
территориясен планлаштыру
проектына кертелә торган
үзгәрешләргә
1 номерлы кушымта

**Кызыл линияләр, линия объектларын план буенча урнаштыру зоналары чикләре, урнашу урыннары үзгәрүгә бәйле рәвештә реконструкцияләнергә тиешле линия объектларын план буенча урнаштыру зоналары чикләре сызымы**


(1 бит)




**ШАРТЛЫ БИЛГЕЛӘР**

| | |
|---|---|
| | Планлаштыру проектын әзерләү гамәлгә ашырыла торган территория чикләре |
| 1 | Характерлы нокта күрсәтелгән линия объектларын план буенча урнаштыру зонасы чиге |
| 1 | Характерлы нокта күрсәтелгән, урнашу урыннары үзгәрүгә бәйле рәвештә реконструкцияләнергә тиешле линия объектларын план буенча урнаштыру зоналары чиге |
| | Гамәлдәге (элек билгеләнгән) кызыл линияләр |
| к1 | Характерлы нокта күрсәтелгән билгеләнә торган кызыл линия |
| Х Х | Гамәлдән чыгарыла торган кызыл линияләр |
| | Автомобиль юлының транспорт хәрәкәт итә торган өлеше |
| | Тротуар/ велосипед юлы |


(2 бит)




**ШАРТЛЫ БИЛГЕЛӘР**

| | |
|---|---|
| | Планлаштыру проектын әзерләү гамәлгә ашырыла торган территория чикләре |
| 1 | Характерлы нокта күрсәтелгән линия объектларын план буенча урнаштыру зонасы чиге |
| 1 | Характерлы нокта күрсәтелгән, урнашу урыннары үзгәрүгә бәйле рәвештә реконструкцияләнергә тиешле линия объектларын план буенча урнаштыру зоналары чиге |
| | Гамәлдәге (элек билгеләнгән) кызыл линияләр |
| к1 | Характерлы нокта күрсәтелгән билгеләнә торган кызыл линия |
| X X | Гамәлдән чыгарыла торган кызыл линияләр |
| | Автомобиль юлының транспорт хәрәкәт итә торган өлеше |
| | Тротуар/ велосипед юлы |

(3 бит)




**ШАРТЛЫ БИЛГЕЛӘР**

| | |
|---|---|
| | Планлаштыру проектын әзерләү гамәлгә ашырыла торган территория чикләре |
| 1 | Характерлы нокта күрсәтелгән линия объектларын план буенча урнаштыру зонасы чиге |
| 1 | Характерлы нокта күрсәтелгән, урнашу урыннары үзгәрүгә бәйле рәвештә реконструкцияләнергә тиешле линия объектларын план буенча урнаштыру зоналары чиге |
| | Гамәлдәге (элек билгеләнгән) кызыл линияләр |
| к1 | Характерлы нокта күрсәтелгән билгеләнә торган кызыл линия |
| X X | Гамәлдән чыгарыла торган кызыл линияләр |
| | Автомобиль юлының транспорт хәрәкәт итә торган өлеше |
| | Тротуар/ велосипед юлы |

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2024 елның 5 апрелендәге
1372 номерлы карары белән
расланган линия объекты
территориясен планлаштыру
проектына кертелә торган
үзгәрешләргә
3 номерлы кушымта

## II. Линия объектын урнаштыру турында нигезләмә
## Урнаштыру планлаштырыла торган линия объектларының, шулай ук урнашу урыны үзгәрүгә бәйле рәвештә реконструкцияләнергә тиешле линия объектларының исемнәре, төп характеристикалары һәм билгеләнеше

Линия объектына автомобиль юлы һәм Татарстан Республикасы Казан шәһәрендә Нокса елгасы аша күпер корылмасы керә.

«Дорожный тыкрыгы һәм Зирекле урамы. Җиңү проспектыннан алып Архитектор Гайнетдинов урамына кадәр юл участогы (1 нче этап)» линия объектын төзү ике этапта каралган:

- 1 нче этап – күпер корылмасы һәм Җиңү проспектыннан Зирекле урамындагы 49 йортка кадәр автомобиль юлы, Архитектор Гайнетдинов урамы һәм Әнәс Таҗетдинов урамы буенча автомобиль юлы;
- 2 нче этап – Зирекле урамындагы 49 йорттан Зирекле урамындагы 2 йортка кадәр автомобиль юлы (линия объекты территориясен планлаштыруның аерым проекты кысаларында башкарыла).

Урамның техник характеристикалары һәм параметрлары СП 42.13330.2016 «Шәһәр төзелеше. Шәһәр һәм авыл җирлекләрен планлаштыру һәм төзү» кагыйдәләр җыелмасы буенча кабул ителде һәм таблицада китерелде.

1 таблица

**Линия объектының техник характеристикалары**

| Техник параметрлары | Үлчәү берәмлеге | Күрсәткечләр | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | 1 урам | 2 урам | 3 урам | 4 урам |
| Урамның категориясе | | Район әһәмиятендәге магистраль урамнар; | Торак төзелеше зонасындагы урамнар | Торак төзелеше зонасындагы урамнар | - |
| Озынлыгы | П.м | 1168 | 200 | 182,94 | 109,6 |
| Автомобиль юлының киңлеге | М | 14 | 10 | 13 | 6 |
| Тротуар киңлеге | Данә | 2 | 3 | 3 | - |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| Велосипед юлы киңлеге | Данә | 1 | 2,5 | 2,5 | - |
| Юл катламы тибы | | Капиталь төр | | | |
| Иң күп йөкләнешле бер күчәргә йөкләнеш | кН | 115 | | | |

Линия объектын план буенча урнаштыру зоналары чикләре гамәлдәге шәһәр төзелеше торышын һәм территорияне фактта файдалануны, шулай ук гамәлдәге җир кишәрлекләрен һәм проектлаштырыла торган объектны тәэмин итүче һәм үзгәртеп корыла торган/автомобиль юлы өлешеннән чыгарыла торган инженерлык челтәрләрен исәпкә алып билгеләнгән.

Линия объектларын урнаштыру зоналары гамәлдәге нормативлар нигезендә билгеләнде. Әлеге объектларны башка ысул белән урнаштыру мөмкин түгел.

Җирләрне бүлеп бирү күләмнәре проектлаштыруның гамәлдәге нормаларын һәм кагыйдәләрен, төзелешне оештыру буенча карарларны исәпкә алып, җирләрне минималь мәҗбүри алу шартларыннан, технологик максатчанлыктан чыгып кабул ителә.

Объектларны төзү, эксплуатацияләү һәм төзекләндерү өчен бүленгән җир полосасы Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2009 елның 2 сентябрендәге 717 номерлы «Автомобиль юлларын һәм (яки) юл сервисы объектларын урнаштыру өчен җирләр бүлеп бирү нормалары турында»гы карары нигезендә кабул ителде.

Эшләр башкару һәм вакытлыча төзелеш хуҗалыгын урнаштыру өчен җирләр бүлеп бирүне төзелеш-монтаж эшләре башланганчы рәсмиләштерү зарур.

Проектта юлга туры килә торган тышкы яктырту челтәрләрен һәм кар-яңгыр суларын чыгару өчен яңгыр канализациясен дә төзү каралган.

Проект буенча проектлаштырылган ябык яңгыр канализациясе системасы белән автомобиль юлыннан өске һәм эрегән суларны Казан шәһәре Башкарма комитетының Тышкы төзекләндерү комитеты хаты буенча проектлаштырылган чистарту корылмаларына җибәрү, аннары Нокса елгасына агызу каралган.

Тышкы яктырту проекты «Челтәр компаниясе» акционерлык җәмгыяте филиалы – Казан электр челтәрләренең техник шартлары нигезендә башкарылды.

**Территорияләрендә линия объектын план буенча урнаштыру зонасы билгеләнә торган Россия Федерациясе субъектлары исемлеге, Россия Федерациясе субъектлары составындагы муниципаль районнар, шәһәр округлары исемлеге, федераль әһәмияттәге җирлекләр, торак пунктлар, шәһәр эчендәге территорияләр исемлеге**

Административ яктан проектлана торган юл Татарстан Республикасы Казан шәһәренең Совет районында урнашкан.

**Линия объектын план буенча урнаштыру зонасы чикләрендә линия объекты составына керә торган капиталь төзелеш объектларын төзүнең, реконструкцияләүнең рөхсәт ителгән чик параметрлары**

Линия объекты составында автомобиль транспорты хәрәкәте өчен 4 полосалы яңа күпер төзү белән күпер корылмасын реконструкцияләү каралган. Проектта гамәлдәге 2 полосалы күпер корылмасын сүтү һәм линия объекты кызыл линияләре чикләрендә Нокса елгасы аша яңа 4 полосалы күпер корылмасы төзү каралган.

Күпернең характеристикалары таблицада күрсәтелде.

2 таблица

**Юл үткәргече техник характеристикалары**

| № т/б | Техник күрсәткеч исеме | Үлчәү берәмлеге | Күрсәткеч |
|---|---|---|---|
| 1 | Күпер корылмасының озынлыгы | м | 183,2 |
| 2 | Күпер корылмасының киңлеге | м | 13,9 |
| 3 | Машина йөрү өлешенең габариты | м | 9,6 |
| 4 | Тротуарларның/хезмәткәрләр йөрү юлларының киңлеге | м | 1,5/0,75 |
| 5 | Тулы буй схемасы | м | (40,6+60+40,6)+33 |
| 6 | Хисап йөкләнешләренә туры килү | - | А14, Н14 |

Линия объектларын план буенча урнаштыру зоналары чикләрендә линия объектлары составына керә торган капиталь төзелеш объектларын рөхсәт ителгән төзүнең, реконструкцияләүнең чик параметрлары билгеләнми.

**Территорияне планлаштыру проектын әзерләү вакытына гамәлдә булган һәм төзелеп килүче саклана торган капиталь төзелеш объектларын (бина, төзелмә, корылма, төзелеше тәмамланмаган объектлар), шулай ук территорияне планлаштыру буенча элек расланган документлар нигезендә төзү планлаштырыла торган капиталь төзелеш объектларын линия объектын урнаштыру белән бәйле рәвештә мөмкин булган тискәре йогынтыдан саклау чараларын гамәлгә ашыру зарурлыгы турында мәгълүмат**

Территорияне планлаштыру проектын әзерләгәндә гамәлдә булган һәм төзелеп килүче саклана торган капиталь төзелеш объектлары (бина, төзелеш, корылма, төзелеш тәмамланмаган объектлар), шулай ук территорияне планлаштыру буенча элек расланган документлар нигезендә төзү планлаштырыла торган капиталь төзелеш объектлары юк.

**Линия объектын урнаштыруга бәйле рәвештә мәдәни мирас объектларын мөмкин булган тискәре йогынтыдан саклау чараларын гамәлгә ашыру кирәклеге турында мәгълүмат**

Планлаштыру проекты чикләрендәге территориядә Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларының (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләрнең) бердәм дәүләт реестрына һәм мәдәни мирас объекты билгеләренә ия булган объектларның дәүләт исәбенә кертелгән мәдәни мирас объектлары юк; сорала торган җирләр реестрга кертелгән мәдәни мирас объектлары территорияләренең расланган чикләрендә, ачыкланган мәдәни мирас объектлары территорияләренең расланган чикләрендә, реестрга кертелгән мәдәни мирас объектларын саклау зоналарының расланган чикләрендә, расланган сак зоналары чикләрендә, тарих һәм мәдәният өчен аерым әһәмияткә ия тарихи җирлекләр территорияләренең расланган чикләрендә урнашмаган; файдалану (чикләү/хокукларын чикләү) режимнары турында белешмәләр юк.

Шуңа бәйле рәвештә мәдәни мирас объектлары территорияләре чикләре схемасы планлаштыру проекты составында китерелми.

Татарстан Республикасы мәдәни мирас объектларын саклау комитетының (алга таба – Комитет) проект территориясендә ачыкланган мәдәни мирас объектларының яисә мәдәни мирас объекты билгеләренә ия объектларның булмавы турында белешмәләре юк. Моны исәпкә алып, заказ бирүче 2002 елның 25 июнендәге 73-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) турында»гы федераль законның 28, 30, 31, 32, 36, 45.1 статьялары нигезендә, җир эшләре башлаганчы, түбәндәгеләрне башкарырга тиеш:

- җир, төзелеш, хуҗалык эшләре һәм башка эшләр башкарылырга тиешле җир кишәрлегенә 73-ФЗ номерлы федераль законның 45.1 статьясында билгеләнгән тәртиптә археологик тикшерүләр уздыру юлы белән тарихи-мәдәни экспертиза үткәрүне һәм финанслауны тәэмин итәргә;

- Комитетка җир, төзелеш, хуҗалык һәм башка эшләр башкарылырга тиеш җир кишәрлегендә мәдәни мирас объекты билгеләре булган объектларның булуы яки булмавын билгеләүче тикшеренү нәтиҗәләрен үз эченә алган документларны, шулай ук әлеге документларга (яки җир кишәрлегенә) дәүләт тарихи-мәдәни экспертизасы бәяләмәсен тапшырырга.

Карап тикшерелә торган территориядә ачыкланган археологик мирас объектлары, шулай ук мәдәни мирас объекты билгеләренә ия объектлар табылган очракта, түбәндәгеләрне башкару зарур:

- проект документлары составында ачыкланган мәдәни мирас объектының сакланышын тәэмин итү турында яисә кырда башкарыла торган археологик коткару эшләрен уздыру турында бүлекне яки ачыкланган мәдәни мирас объектының сакланышын тәэмин итү буенча проект яисә уздырыла торган эшләрнең күрсәтелгән мәдәни мирас объектына йогынтысын бәяләүне үз эченә алган кырда башкарыла торган археологик коткару эшләрен уздыру планын эшләргә (алга таба – ачыкланган мәдәни (археологик) мирас объектының сакланышын тәэмин итү буенча чараларны нигезли торган документлар яисә документлар бүлеге);

- ачыкланган мәдәни мирас объектының сакланышын тәэмин итү буенча чараларны нигезли торган документлар яисә документлар бүлеге буенча дәүләт тарихи-мәдәни экспертизасы бәяләмәсен алырга һәм аны, килештерү өчен, күрсәтелгән документлар белән бергә Комитетка тапшырырга;

- ачыкланган мәдәни мирас объектларының сакланышын тәэмин итү буенча чараларны нигезли торган килештерелгән документларда күрсәтелгән чараларны гамәлгә ашыруны тәэмин итәргә.

## Әйләнә-тирә мохитне саклау чараларын гамәлгә ашыру зарурлыгы турында мәгълүмат

Казан шәһәре Башкарма комитетының 2024 елның 5 апрелендәге 1372 номерлы карары белән расланган «Дорожный тыкрыгы һәм Зирекле урамы. Җиңү проспектыннан алып Архитектор Гайнетдинов урамына кадәр (1 нче этап) юл участогы» объектында табигатьне саклау чараларына 2002 елның 10 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы «Әйләнә-тирә мохитне саклау турында»гы федераль законның, Россия Федерациясе Җир кодексының, ГОСТ Р 59070-2020 «Әйләнә-тирә мохитне саклау. Бозылган һәм нефть белән пычранган җирләрне рекультивацияләү. Терминнар һәм билгеләмәләр», ГОСТ Р 59060-2020 «Әйләнә-тирә мохитне саклау. Җирләр. Рекультивацияләү максатыннан бозылган

җирләрне классификацияләү» һәм башкаларның гамәлдәге норматив таләпләре нигезендә оператив һәм кисәтү чаралары кертелергә тиеш.

Планлаштырыла торган эшләр линия объектын план буенча урнаштыру зонасы чикләрендә генә башкарылачак.

Җирле әһәмияттәге махсус сакланылучы табигать территорияләре, урман-парк яшел поясы, зиратларның, түләмә чиреннән үлгән терлекләр зиратларының һәм биометрик чокырның санитар-яклау зоналары тикшеренүләр үткәргән кишәрлекләре чикләрендә юк.

## Территорияне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау, шул исәптән янгын куркынычсызлыгын һәм гражданнар оборонасын тәэмин итү чараларын гамәлгә ашыру зарурлыгы турында мәгълүмат

РФ Шәһәр төзелеше кодексының 48.1 статьясы нигезендә автомобиль юлы аеруча куркыныч, техник яктан катлаулы һәм уникаль җитештерү циклы объекты булып саналмый һәм үз составында куркыныч производстволар һәм аларның участоклары юк. Объектта куркыныч матдәләр дә юк. Димәк, куркыныч матдәләрне авария хәлендәге чыгаруларны (ташлауларны) локальләштерү буенча карарлар проектлауга бирем белән билгеләнми һәм проектта каралмый.

1997 елның 21 июледәге 116-ФЗ номерлы «Куркыныч җитештерү объектларының сәнәгать куркынычсызлыгы турында»гы федераль закон нигезендә автомобиль юллары куркыныч җитештерү объектларына керми.

Төзелеш корылмалары җимерелүгә бәйле аварияләр үсешен кисәтү эксплуатацияләүче оешма көчләре белән даими күзәтү һәм мониторинглау хисабына һәм, авария белән бәйле вазгыять барлыкка килгән очракта, Дәүләт автоинспекциясе органнары белән берлектә эксплуатацияләүче оешма карары нигезендә автомобиль юлы буенча хәрәкәтне туктатып (чикләп), мондый аварияләрнең башлангыч билгеләрен ачыклау белән ирешелә.

Проектлаштырыла торган корылмаларның янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү өчен, шул исәптән проектлаштыруның алдагы этапларында да, 2009 елның 30 декабрендәге 384-ФЗ номерлы «Биналарның һәм корылмаларның куркынычсызлыгы турында техник регламент» федераль законы белән билгеләнгән чараларны гамәлгә ашыруны күздә тоту зарур.

Проектлана торган линия объекты территориясенә якын янгыннан саклау бүлекчәсе – Красная Позиция урамы, 3Б адресы буенча урнашкан 6 номерлы янгыннан саклау часте.

Линия объектының карап тикшерелә торган территориясе мөмкин булган

җимерелүләр, химик һәм радиоактив зарарлану, катастрофик су басу зоналарына эләкми. Проектлана торган объектлар урнашу районында куркыныч табигый процесслар (ишелүләр, сил ташкыннары, кар ташкыннары һ.б.) булмый.

Шул рәвешле, проектлаштыруның алдагы стадияләрендә «Гражданнар оборонасы чаралары, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне кисәтү чаралары исемлеге» бүлеген эшләү зарурлыгы юк.